КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 сентябрь г.Казань № 1157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карары белән расланган 2022 елның III – IV кварталларында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшер-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшер-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2023 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елның III – IV кварталларында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшер-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшер-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 август, 557 нче; 2018 ел, 15 сентябрь, 784 нче;

2019 ел, 18 март, 191 нче; 2019 ел, 28 август, 709 нчы; 2020 ел, 20 июль, 609 нчы; 2021 ел, 21 май, 358 нче; 2022 ел, 27 апрель, 399 нчы; 2023 ел, 27 март, 363 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 елның III – IV кварталларында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшер-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшер-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2023 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибенә, 9.1 пунктның беренче абзацындагы «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин